*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы*
*муниципаль бюджет урта гомуми белем бирү учреждениесе*
*Симәк урта гомуми белем бирү мәктәбе*
*5 нче сыйныф җитәкчесе*
***Мирасова Гөлнур Рәмиз кызы***

**Тема: “Олимпияданы каршылыйбыз”**

дип исемләнгән 5 нче сыйныф өчен тәрбия сәгате.

**Максат:** - Олимпия уеннарының тарихы белән таныштыру.

- Сәламәт яшәүгә омтылыш тәрбияләү.
- Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү, олылар каршында матур итеп чыгыш ясарга өйрәтү.

**Материал:** ноутбук, проектор, рәсемнәр, презентация.

***Дәрес барышы:***

- Хәерле көн, укучылар, укытучылар һәм килгән кунаклар. Укучылар, шушы рәсемгә карагач сездә нинди фикерләр туа?

*Рәсемгә карап укучылар белән фикер алышу.*

- Бүген без сезнең белән беренче олимпия уеннары кайчан барлыкка килгән, XXII нче җәйге һәм кышкы олимпия уеннары турында сөйләшербез. Шуның өчен “Олимпия” шәһәренә сәяхәткә барырбыз.

Беренче Олимпия уеннары б.э.к. 776 елда үткәрелә башлаган. Ул Борынгы Грециядә булган һәм анда кол булмаган грек ир кешеләре генә катнаша алган. Олимпия уеннарына катнашучылар 1 ай буена әзерләнгәннәр. Бу уеннарда хатын-кызларга катнашырга да, карап торырга да ярамаган. Алар өчен аерым вакытта, аерым уеннар үткәрелгән.

- Укучылар, нәрсә соң ул Олимпия уеннары?
- Россия спортсменнары Олимпиядада беренче тапкыр 1908 елда катнашканнар. Ул Лондон шәһәрендә булган. Анда 8 кеше катнашкан. Николай Панин-Коломенский беренче олимпия чемпионы була.

*1 укучы класс алдында чыгыш ясый.*

- XXII нче җәйге Олимпия уеннары Мәскәү шәһәрендә 19 нчы июльдән 3 нче августка кадәр 1980 нче елны уза. Совет Социалистик Республикалар Союзы (СССР) территориясендә мондый уеннар беренче тапкыр уздырыла. Шул җәйге олимпия уеннарында 80 ил, 5179 спортсмен катнаша. 14 көн эчендә спортсменнар 74 олимпия, 39 европа һәм 36 дөнья рекорды куя. СССР катнашып барлыгы 195 медаль яулый: шуларның 80 – алтын, 69 – көмеш, 46 – бронза. Җәйге олимпия уеннарының талисманы – Аю.

*2 нче укучы класс алдында чыгыш ясый.*

- Озакламый Россия Федерациясенең Краснодар краенда Сочи шәһәрендә XXII нче Олимпия уеннары булачак. Анда барлык ил халыклары көч сынаша. Мондый төр зур спорт ярышының Россиядә үтүе белән горурлана алабыз.

2014 елда Сочи шәһәрендә XXII нче Олимпия уенннары 7-23 февральдә үтәчәк, ә паралимпия уеннары 7-17 мартта узачак.

Олимпия уеннарының талисманы Ак Леопард, Ак Аю һәм Ак Куян. Паралимпия уеннарының талисманы Кар бөртеге һәм Нур.

- Нәрсә ул паралимпия уеннары? *(Укытучы сорый)*
- Әйе, укучылыр, бу Олимпия уеннарында физик яктан мөмкинлекләре чикләнгә кешеләр катнашалар.
- Олимпия уеннарының символы бер-берсенә бәйләнгән төрле төсле 5 боҗра.
- Девизы: “ТИЗРӘК, БИЕГРӘК, КӨЧЛЕРӘК!”
- Кышкы уеннар булгач, нинди ярышлар булыр дип уйлыйсыз? *(Чаңгы спорты, конькобежный спорт, бозда хоккей, биатлон).*
- Укучылар, Олимпия уеннарында катнашу өчен нинди сыйфатлар хас булырга тиеш? (*Укучыларның җавабы).*
- Барыгызга да бик зур рәхмәт, дәрес тәмам.